# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Халыкны адреслы җәмгыяви яклау буенча республика фондын, халыкны җәмгыяви яклау буенча җирле фондларны, ветераннарның һәм гарипләрнең җәмәгать оешмаларын мөлкәткә салымнан, кайбер төр һәм кайбер төркем товарларга акцизлардан азат итү турында

<u>1 статья.</u> Халыкны җәмгыяви яклауны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүне яхшырту максатларында Татарстан Республикасының Халыкны адреслы җәмгыяви яклау буенча республика фондын, халыкны җәмгыяви яклауның һәм ярдәм күрсәтүнең җирле фондларын, ветераннарның һәм гарипләрнең җәмәгать оешмаларын бюджетка мөлкәт салымы түләүдән, Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан билгеләнә торган кайбер төр һәм кайбер төркем товарларга акцизларны түләүдән азат итәргә. Тотылмый калган акчалар устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җибәрелә.

<u>2 статья.</u> Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 июне